# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Нефть һәм газ турында

Нефть һәм газ - Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының төп өлеше һәм ул - республика халкы байлыгы. Нефть һәм газ чыгару, транспортлау һәм эшкәртү - республиканың икътисадый мөстәкыйльлеген билгеләүче һәм Татарстан Республикасындагы социаль-икътисадый хәлнең тотрыклылыгына тәэсир итүче сәнагатьнең мөһим состав өлешен тәшкил итәләр. Нефть һәм газны разведкалау, чыгару, транспортлау, куллану һәм сату мәсьәләләрен законнар белән җайга салу дәүләтнең мөһим бурычы булып тора.

Закон нефть һәм газ чыганакларын эшкәрткәндә, нефть һәм газ чыгарганда барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала, эшләрнең нәтиҗәле файдаланылышын һәм иминлеген тәэмин итә, Татарстан Республикасы халкы мәнфәгатьләрен яклый һәм җир асты байлыклары милекчесенең һәм алардан файдаланучының хокукларын саклый.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Татарстан Республикасында чыгарылучы нефть - үзара бәйле һәм бер-берсенә үзара тәэсир итүче углеводород (алкан, ароматик, нафтен), кислород, күкерт һәм металл катышлы кушылмаларның күп компонентлы табигый катнашмасы ул. Авыр, үтә ябышкак нефть һәм табигый битумнар бик үзле булалар һәм химик составы ягыннан бер-берсенә якын торалар.

Табигый газ - Татарстан Республикасында газ чыганакларын-

нан чыгарылучы газ ул; иярчен газ - Татарстан Республикасында чыгарылган нефтьтән сепарацияләү юлы белән алынган газ ул.

Роялти - нефть һәм газ булган җир асты урыннарыннан лицензия килешүе гамәлдә булган барлык вакыт эчендә файдалану хокукы өчен даими түләүләр ул. Роялти продукцияне сату хакыннан процентлар рәвешендә исәпләнә.

Продукцияне бүлешү турындагы килешү - шартнамә (контракт) ул,аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты инвесторга килешүдә күрсәтелгән җир асты кишәрлегендә түләүле һәм билгеле бер чорга нефть һәм газ эзләү, разведкалау, чыгару өчен һәм шулар белән бәйле эшләр алып бару өчен махсус хокуклар бирә, ә инвестор исә әлеге эшләрне үз хисабына һәм үз тәвәкәллегенә таянып башкарырга йөкләмә ала.

Нефть һәм газны магистраль торба аша үткәрү транспорты объектлары - кулланучыларга нефть һәм газ китереп торучы торбаүткәргечләрнең тупламасы ул.

Транспорт хезмәте күрсәтүләр - нефть үткәрү транспорты өчен, суднолар бортына (бортыннан) һәм тимер юл цистерналарына (тимер юл цистерналарыннан) нефть тутыру (агызу) өчен махсус билгеләнгән объектларда нефтьне кабул итү, агызу, урнаштыру, бергә кушу, саклау, тапшыру һәм тутыру буенча үрнәк җитештерү операцияләре ул.

Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы - газ чыгарганда, транспортлаганда, саклаганда, эшкәрткәндә, бүлгәндә үзара оешкан төстә һәм вазыйфаи бәйле предприятиеләр җыелмасы ул.

2 статья. Нефть һәм газ эзләү, разведкалау һәм чыгару, аларны транспортлау һәм саклау барышында барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу

Нефть һәм газ эзләү, разведкалау һәм чыгару, аларны саклау һәм Татарстан Республикасы территориясе буйлап транспортлау барышында барлыкка килүче мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнар белән җайга салына.

3 статья. Нефть һәм газ ресурсларына хуҗа булу

Җир астындагы табигый халәттәге нефть һәм газ Татарстан Республикасының дәүләт милке була.

Җир астыннан чыгарылган нефть һәм газ дәүләт милкендә, шәхси милектә, шул исәптән чит ил юридик затлары һәм гражданнары белән уртак милектә булырга мөмкин.

Лицензия хуҗасы тарафыннан лицензия шартлары буенча җир астыннан чыгарылган һәм саклау өчен, скважина дебитын һәм нефть чыгару күрсәткечләрен арттыру өчен җир астына кабат кайтарылган нефть һәм газ җир өстенә чыгарылган нефть һәм газ буларак караладар.

4 статья. Нефть һәм газ резерв чыганакларының республика фонды

Нефть һәм газның стратегик запасларын булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты нефть һәм газ резерв чыганакларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланучы республика фондын оештыра. Нефть һәм газ резерв чыганакларының республика фонды составына разведкаланган һәм файдалануга әзерләнгән нефть һәм газ чыганаклары кертелә.

## II бүлек. Продукцияне бүлешү турындагы килешүләрне төзү һәм үтәү

5 статья. Продукцияне бүлешү турында килешү

Нефть һәм газны эзләү, разведедкалау һәм чыгару, җитештерелгән продукцияне бүлешү барышында, шулай ук аны транспортлау, эшкәртү вакытында барлыкка килүче мөнәсәбәтләр продукцияне бүлешү турындагы килешү (алга таба - килешү) белән җайга салынырга мөмкин. Продукцияне бүлешү турындагы килешү якларының хокуклары һәм йөкләмәләре әлеге Закон, шулай ук Россия Федерациясе законнарының Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Та-

тарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында"гы шартнамәгә каршы килмәгән өлешләре нигезендә билгеләнә. Продукцияне бүлешү турындагы килешү шартнамә була, аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты эшкуарлык эшчәнлеге субъектына (алга таба - инвесторга) килешүдә күрсәтелгән җир асты кишәрлегендә түләүле һәм билгеле бер чорга нефть һәм газ эзләү, разведкалау, чыгару өчен һәм шулар белән бәйле эшләр алып бару өчен махсус хокуклар бирә, ә инвестор исә әлеге эшләрне үз хисабына һәм үз тәвәкәллегенә таянып башкарырга йөкләмә ала. Килешү җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле барлык кирәкле шартларны, шул исәптән җитештерелгән продукцияне килешү төзегән яклар арасында бүлешү шартларын һәм тәртибен билгели. Җир асты кишәрлегеннән файдалану өчен бирелүче һәм аннан килешүдә билгеләнгәнчә файдалану хокукын раслаучы лицензия килешүгә имза салынганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә аның кушуы буенча җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итүче республика органы тарафыннан инвесторга тапшырыла. Лицензия килешүнең гамәлдә булу чорына бирелә һәм килешү шартлары нигезендә озынайтылырга яки яңадан рәсмиләштерелергә тиеш яисә үз көчен югалта. Продукцияне бүлешү шартларында законнар нигезендә файдалану хокукы белән бирелүче җир асты байлыклары кишәрлекләренең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

6 статья. Килешүдә катнашучы яклар

Түбәндәгеләр килешүдә катнашучы яклар булалар:

Татарстан Республикасы, килешүләрдә аның исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты эш йөртә; инвесторлар - нефть һәм газ эзләүгә, разведкалауга һәм чыгаруга үз акчаларын, заем яисә җәлеп ителгән акчаларын кертүче һәм килешү шартлары нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланучы Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән Татарстан Республикасы гражданнары, чит ил гражданнары, юридик затлар һәм юридик затларның уртак эшчәнлек турындагы шартнамә нигезендә төзелүче берләшмәләре.

Килешүнең гамәлдә булу чоры законнар нигезендә яклар тарафыннан билгеләнә.

<u>7 статья.</u> Килешүләрне үтәгәндә салымнар һәм түләүләр

Табышка салымнан һәм җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрдән гайре, инвестор килешүнең гамәлдә булу чорында салымнардан, җыемнардан, акцизлардан һәм законнар нигезендә Татарстан Республикасының Республика бюджетына кертелүче башка мәҗбүри түләүләрдән азат ителә. Әлеге салымнарны, җыемнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне алу килешү шартларында продукцияне бүлешү белән алмаштырыла. Килешүләрне төзү һәм үтәү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслanучы махсус нигезләмәдә билгеләнә.

**Ш бүлек.**
**Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү**

<u>8 статья.</u> Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү төрләре

Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдалану, әлеге Законның 10 статьясында каралган очраклардан гайре, түләүле була.

Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түбәндәге төрдәге түләүләр ясала:

а) конкурста (аукционда) катнашкан өчен җыем;

б) лицензияләр биргән өчен җыем;

в) нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр;

г) нефть һәм газ запасларын торгызуга һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыруга түләүләр;

д) акцизлар.

Моннан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар салымнар, җыемнар һәм законнарда каралган башка түләүләр кертәләр. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга әлеге Законның 12 статьясы нигезендә җир асты байлыкларын бик нык киметкән өчен

түләүләргә скидкалар ясала. Соңгы стадиядә объектив билгеләнгән һәм запаслардан нәтиҗәле файдалану шартларын бозуга бәйле булмаган түбән нәтиҗә белән эшкәртелүче ятма һәм аның бер өлеше кимегән җир асты байлыкларына керә. Кимегән җир асты байлыкларын эшкәрткән өчен түләүләр билгеләгәндә скидка ясала.

Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланучылардан законнарда каралмаган түләүләр алу рөхсәт ителми.

Продукцияне бүлешү шартларында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты белән һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучылар арасында килешүләр төзегәндә, чыгарылган нефтьне һәм газны бүлешү карала. Мондый килешүләрнең шартлары буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы законнар нигезендә салымнар түләүдән һәм башка түләүләрдән азат ителергә мөмкин.

9 статья. Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр

Җир асты байлыкларыннан файдаланучылардан нефть һәм газ ятмаларын эзләгән, разведкалаган, аларны чыгарган һәм нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан башка максатларда файдаланган өчен түләүләр алына.

Эзләнү һәм разведкалау эшләрен башкарган өчен, шулай ук нефть һәм газ чыгарган өчен, нефть һәм газ катламнары запасларының санына һәм сыйфатына, нефть һәм газ ятмалы төп катламнарның тирәнлегенә, скважиналарның башлангыч дебитына, хәвефлелек дәрәҗәсенә (С2 категорияле запаслар өлеше), нефть һәм газны транспортлаучы якындагы магистраль торбаүткәргечләргә кадәрге ераклыкка, башка икътисадый-географик шартларга карап, түләүләр билгеләнә.

Нефть һәм газ чыгарган өчен түләүләр аларны чыгаруның үзкыйммәтенә кертелә һәм сатылган чимал хакының өлеше буларак билгеләнә.

Роялтиның зурлыгы һәм кертемнәрне Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга бүлү Татарстан Республикасының республика бюджетын раслаганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

10 статья. Нефть һәм газ ятмалы җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрдән азат итү

Түбәндәге җир асты кишәрлекләреннән файдаланучылар чыгарылган нефть һәм газ өчен түләүләрдән азат ителергә мөмкин:

әшкәртелүче кишәрлекләрдән физик, химик, физик-химик, газ, җылылык, микробиологик һәм гидродинамик ысуллар нигезендә нефть чыгарганда;

нефть, газ һәм су чыгарганда ияреп чыгучы компонентларны сатканда, лицензиядә аларны чыгару каралмаган булса гына;

яңа технологияләрне гамәлгә керткәндә нефть һәм газ югалтуны киметү исәбеннән алынучы продукциядән;

техник-икътисадый нигезләнгән документларда яисә яңа чыганакларны әшкәртү буенча проект документларында билгеләнгән капитал салуларны каплау чорына әлеге чыганакларны башлангыч чорларында үзләштергәндә;

яңа технологияләрне сынау буенча тәҗрибә-сәнәгать эшләрен башкару вакытында нефть чыгарганда;

ияреп чыгучы нефть газын чыгарганда.

Түләүләрдән азат итү хакындагы карарны, әлеге статья нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслау шарты белән, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты кабул итә.

11 статья. Нефть һәм газ запасларын ишәйтү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен түләүләр

Нефть һәм газ запасларын ишәйтү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен түләүләр ставкасы сатылган нефть һәм газ хакының бер өлеше буларак билгеләнә һәм продукциянең үзкыйммәтенә кертелә.

Нефть һәм газ запасларын ишәйтү, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен түләүләр Татарстан Республикасының Минераль байлыклар запасын ишәйтү һәм казылма байлыкларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча бюджеттан тыш дәүләт фондында тупланa.

Углеводород чыгаручы предприятиеләрнең чимал базасын ныгыту йөзеннән, әлеге статьяда каралган түләүләрнең бер өлеше

углеводород чималын чыгаручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар карамагында калырга мөмкин, һәм бу өлеш файдалы казылмаларның запасларын ишәйтү һәм аларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру өчен тотылырга мөмкин. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар карамагында калган түләүләр күләме Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Геологик өйрәнү эшләре һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру эшләре нефть һәм газ запасларын ишәйтү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен түләүләрнең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларда калучы өлеше исәбеннән лицензия хуҗалары тарафыннан мөстәкыйль финансланырга мөмкин.

Нефть бирүчәнлекне арттыру ысуллалары исәбенә нефть чыгарганда, чыгаруы кыен булган, кондицияле булмаган, балanстан тыш чыгарылган, элек исемлектән төшеп калган нефть запасларын чыгарганда, техник-икътисадый нигезләүләрдә яисә яңа чыганакларны эшкәртү буенча проект документларында билгеләнгән капитал салуларны каплау чорына әлеге чыганакларны башлангыч стадиясендә үзләштергәндә түләүләр алынмый.

Әгәр геологик өйрәнү эшләре һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру эшләре өчен бүленгән средстволар җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан яңа технологияләр куллану исәбенә экономияләнсә, җир асты байлыкларының конкрет кишәрлегендә башкарылучы тиешле төрдәге эшләрнең объектив барлыкка килгән (соңгы 5 елда) нәтиҗәлелеген арттырганда, экономияләнгән средстволар җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятие табышына кертелә һәм билгеләнгән ставка буенча табышка салым салына.

Эшкәртелүче чыганакларны үз средстволары исәбеннән өйрәнүне һәм разведкалауны башкаручы яисә дәүләтнең тиешле санда запаслар өйрәнүгә һәм разведкалауга тоткан барлык чыгымнарын тулысынча түләүче җир асты байлыкларыннан файдаланучылар. тиешле чыганакларны эшкәрткәндә нефть һәм газ запасларын ишәйтү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен түләүләрдән азат ителергә мөмкин. Запасларны ишәйтү өчен бүленгән суммаларның бер өлеше Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы нигезләмә нигезендә нефть һәм газ чыганакларын ачкан һәм разведкалаган өчен бүләкләүләрне башкарырга җибәрелә.

12 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү ташламалары

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү ташламалары чыганакларны эшкәртүнең алдан ук түбән нәтиҗәле булуын белгән килеш (нефть чыганаклары катламнарының запаслары бик нык кимегәндә, составында 85 проценттан артыграк су булганда һәм нык ябышучан нефть чыганакларын, түбән коллектор сыйфатлы ятмаларны эшкәрткәндә, түбән калдык запаслардан файдалы казылмалар чыгарганда һәм скважиналарның зыян китерүче аз дебитлы фондыннан нефть чыгарганда) нефть чыгаручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга чыгарылган нефть һәм газ өчен бирелергә мөмкин.

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү ташламалары бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү ставкалары күләмен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгели.

13 статья. Акцизлар

Җир асты - геологик һәм икътисадый-георафик сыйфатламалары чагыштырмача яхшырак булган чыганаклардан алынган нефтькә һәм газга акцизлар законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнергә мөмкин.

Чыганакларны эшкәртүнең алдан ук түбән нәтиҗәле булуын белгән килеш (нефть чыганаклары катламнарының запаслары бик нык кимегәндә, составында 85 проценттан артыграк су булганда һәм нык ябышучан нефть чыганакларын, түбән коллектор сыйфатлы ятмаларны эшкәрткәндә, түбән сыйфатлы калдык запаслардан нефть һәм газ чыгарганда, зыян китерүче аз дебитлы скважиналардан нефть чыгарганда, эшкәртүнең өченчел ысуллары белән нефть чыгарганда), нефть һәм газ чыгарганда, акцизлар алынмаска тиеш.

14 статья. Нефть чыгаруны арттыруны кызыксындыру

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән дәүләт йөкләмәсен арттырып чыгарылган нефть өчен

түләү өлешендә акциалар, нефть чыгаруның тулаем республика буенча ирешелгән дәрәҗәсен саклаган килеш, Татарстан Республикасының республика бюджетына, нефть чыгарган районнарның җирле бюджетларына, нефть чыгаручы җитештерү бүлекчәләренең (оешмаларының) счетына күчерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән дәүләт йөкләмәсен арттырып чыгарылган нефть өчен түләү өлешендә роялти, нефть чыгаруның тулаем республика буенча ирешелгән дәрәҗәсен саклаган килеш, Татарстан Республикасының республика бюджетына, нефть чыгарган районнарның җирле бюджетларына, нефть чыгаручы җитештерү бүлекчәләренең (оешмаларының) счетына күчерелә.

Средстволарны Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар, нефть чыгаручы китештерү бүлекчәләре (оешмалары) арасында бүлү күләме Татарстан Республикасының республика бюджетын расллаганда билгеләнә.

## IV бүлек.
## Нефть һәм газ эзләү, бәяләү һәм чыгару максатларында җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләүнең үзенчәлекләре

<u>15 статья.</u> Лицензия. Лицензия килешүе

Лицензиядә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

Катгый шартлар:

- җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрнең максатчыл билгеләнеше турында белешмәләр;
- файдалануга бирелүче җир асты кишәрлегенең һәм эшләр алып барыр өчен бүленгән кирәкле җир кисәгенең пространстводагы бәйләнеше;
- лицензиянең гамәлдә булу вакытлары.

Яклар килешүе белән билгеләнүче шартлар:

- нефть һәм газ чыганакларын тәэкләндерүнең һәм эшкәртүнең технологик схемаларын һәм проектларын, әлеге эшләрнең гомуми һәм еллык программаларын төзү тәртибе һәм вакыты, шулай ук күрсәтелгән схемаларны, проектларны һәм программаларны финанслау тәртибе һәм вакытлары;

- нефть һәм газ чыгаруның килештерелгән кимәлләре, алар билгеле бер вакытта технологик схема яисә эшкәртү проекты буенча төгәлләштереләләр, йә нефть һәм газ чыганакларының минималь күләмнәре буенча йөкләмәләр, нефть һәм газ чыгару, скважиналарны гамәлгә кертү вакытлары һәм башкалар;
- иярчен газны файдалану буенча йөкләмәләр;
- нефть һәм газны транспортлау шартлары;
- лицензия килешүен үтәүгә бәйле рәвештә төзелгән һәм кулланылучы мөлкәткә милекчелек хокукы, лицензиянең гамәлдә булу чоры үткәннән соң мөлкәтне юк итү шартлары һәм тәртибе;
- килешү асылы буенча якларның хокуклары һәм бурычлары;
- җир асты байлыкларыннан файдаланучылар теркеменә лицензия бирелгәндә җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның гамәлләрен җайга салу тәртибе;
- җир асты байлыкларыннан файдаланганда кирәк булган геологик мәгълүматларны алу хокукы;
- җир астына ташлана торган җитештерү калдыкларының, катлам суларының һәм агып төшүче суларның күләмнәре һәм төрләре, әлеге эшләрне башкару шартлары;
- сәнәгать объектларының иминлеген тәэмин итү, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигатьне торгызу эшләрен башкару буенча йөкләмәләр;
- гомуми инфраструктура объектларыннан файдалану тәртибе;
- нефть һәм газ чыганакларын эшкәрткәндә территориядән файдалану тәртибе;
- җир асты байлыкларыннан, җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләүләр;
- чыгымнарны түләттерү һәм продукцияне бүлешү шартлары;
- лицензия килешүе шартларының үтәлешен тикшереп тору процедурасы;
- лицензия килешүенең гамәлдә булу чорын озайту, аны туктатып тору яисә вакытыннан алда туктату шартлары;
- ликвидация эшләрен башкару һәм финанслау тәртибе;
- иминләштерү шартлары;
- якларның хокукый һәм икътисадый җаваплылыгы гамәлләре;
- кичектергесез хәлләр килеп чыкканда, лицензия килешүенең гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору тәртибе;
- бәхәсләрне карау тәртибе.

Лицензия килешүенә гамәлдәге законнарга каршы килмәүче һәм лицензиядә каралган конкрет эшләрне башкару үзенчәлекләрен исәпкә алып билгеләнүче башка нигезләмәләр дә өстәлергә мөмкин.

Лицензия килешүе нигезләмәләре ул гамәлдә булган барлык чорга үз көчен саклыйлар һәм якларның язма рәвештәге килешүләре буенча гына үзгәртелергә мөмкин, моңа әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм техник иминлек буенча үтәлеше мәҗбүри булган яңа нормалар урнаштыручы яңа кабул ителгән законнар нигезендә үзгәртелергә тиешле шартлар керми.

Әгәр лицензия килешүе төзелгәннән соң законнар яисә башка норматив хокукый актлар тарафыннан лицензия хуҗасының хәлен начарайтырлык шартлар урнаштырылса, лицензия килешүе нигезләмәләренә лицензия килешүенә имза салынганда каралган коммерция нәтиҗәләренә ирешерлек үзгәрешләр кертелә.

<u>16 статья.</u> Лицензияләрнең үзенчәлекләре

Нефть һәм газ эзләү, разведкалау, бәяләү буенча һәм тәҗрибә өчен аларны чыгару буенча эшләр башкару хокукы бер үк лицензия белән таныклана.

Нефть һәм газ ятмалары булган җир асты байлыкларыннан файдалануның берничә төрен (нефть һәм газ эзләү, разведкалау һәм чыгару) үз эченә алган лицензияләр бирү дә рөхсәт ителә.

Физик затлар да, юридик затлар да лицензия хуҗасы була алалар.

Җир асты байлыкларыннан геологик өйрәнүгә (эзләүләргә һәм бәяләүгә) лицензия түбәндәгеләрне башкару хокукын күз алдында тота:

геологик кишәрлек территорияләре чикләрендә аларның бөтенлеген бозмыйча, җир асты байлыкларын геофизик тикшерүне;

лицензияләнгән кишәрлекләр чикләрендә разведкалау скважиналары челтәрен төзүне, бу вакытта һәр скважина төзү өчен бирелгән җир кишәрлеген рәсмиләштерү, мондый скважиналарны дренлаштыру зоналарында нефть һәм газның сәнәгать запасларын бәяләү йөзеннән, скважиналарны сынап карау өчен мөмкинлекләр тудыру мәҗбүри;

перспективалы геологик объектларны сәнәгать өчен кирәкле

нефть һәм газ ятмалары булуга сынап карауны, бу вакытта дренлаштырылган разведкалау скважиналары зоналарындагы нефть һәм газның бәяләнгән сәнәгать запасларының иң чик мөмкин дәрәҗәсендә һәм лицензия килешүендә күрсәтелгән кадәр генә нефть һәм газ чыгарылырга мөмкин, әмма соңыннан бу запасларга дәүләт экспертизасы үткәрелергә һәм алар тиешле хакыйкый категория нигезендә файдалы казылма запасларының дәүләт балансына кертеләргә тиеш;

нефть һәм газ запасларының хакыйкыйлыгын арттыру йөзеннән нефть һәм газ чыганакларын өстәмә геологик өйрәнүне, бу вакытта файдалы казылмаларның дәүләт балансында саналган иң чик мөмкин күләме кадәр генә нефть һәм газ чыгарылырга тиеш һәм соңыннан нефть һәм газ запасларының хакыйкый күләмнәрен һәм категорияләрен билгеләү өчен тиешле материалларны тапшыру мәҗбүри.

Җир асты байлыкларыннан геологик өйрәнүгә лицензия геологик үлчәмнәрне кәгазьгә төшерү, эзләү-разведкалау эшләрен башкару хокукын, шулай ук нефть һәм газ ятмалары булган җир асты байлыкларыннан турыдан-туры файдалану белән бәйле геологик һәм геологик-технологик тикшеренүләрнең (геофизик, гидрогеологик, сейсмик, фәнни, тематик, махсус) кайбер төрләрен башкару хокукын таныклый.

Нефть һәм газ чыгаруга лицензия аның хуҗасына түбәндәгеләрне башкару өчен махсус хокуклар бирә:

лицензияләнгән кишәрлек чикләрендә нефть һәм газ разведкалау, чыгару һәм разведкалап бетерү;

нефть һәм газдан иярчен компонентларны аерып алу һәм күрсәтелгән компонентларны эзерләү һәм беренчел эшкәртү;

катлам басымын бер үк дәрәҗәдә тоту һәм иярчен компонентларны аерып алу өчен лицензияләнгән стратиграфик киңлекләрдән катлам суларын суыртып алу, әлеге компонентларны эзерләү һәм эшкәртү.

Нефть һәм газ чыгаруга лицензия хуҗасы нефть һәм газны эшкәртү объектларыннан саклагычка кадәр һәм саклагычтан магистраль торбаүткәргеч системасына кушылу пунктларына кадәр транспортлау өчен торбаүткәргечләр кору хокукына ия була.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә лицензия хуҗасы нефть һәм газ чыганагын ачкан очракта, әлеге лицензияне биргән

органнарга чыганакны эшкәртү проектын тапшырырга тиеш, анда исә продукцияне гамәлгә ашыру буенча фаразлау булырга тиеш. Мондый лицензиядә чыганакны яисә аның бер өлешен консервацияләүнең тәртибе һәм шартлары каралырга мөмкин. Мондый чыганакны консервацияләү чоры чыганактан файдалану вакытына һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу вакытына кертелми. Иярчен күкерт водороды күп булган нефть чыганаклары консервацияләнергә мөмкин.

Әгәр лицензия хуҗалары лицензия шартларын, лицензия килешүләрен һәм гамәлдәге законнарны бозмасалар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары лицензия хуҗаларына җир асты байлыкларыннан файдалану хокукларын гамәлгә ашырганда комачауламаска тиешләр.

17 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә (эзләүләргә һәм бәяләүгә) һәм нефть, газ чыгаруга лицензияләр бирү үзенчәлекләре

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә (эзләүләргә һәм бәяләүгә) һәм нефть, газ чыгаруга лицензияләр бирү конкурслар һәм аукционнар нигезендә башкарыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланырга теләүчеләрне конкурс яисә аукцион рәвешендә сайлап алуның тиешле критерийлары исемлеге, шулай ук шартнамә мөнәсәбәтләре рәвеше лицензия бирүче органнар тарафыннан билгеләнә.

Конкурслар яисә аукционнар үткәргәндә җир асты байлыкларыннан файдаланырга теләүчеләрне сайлап алуның төп критерийлары түбәндәгеләр була:

эзләү һәм бәяләү эшләрен башкару темплары һәм нәтиҗәлелеге;

нефть һәм газ байлыкларының һәм запасларының исәпләүләргә нигезләнгән күләме;

нефть һәм газ чыгара башлауның һәм аларны эшкәртүнең технологик схемасы билгеләгән максималь дәрәҗәсенә ирешү вакытлары;

эшләрне башкаруның техник дәрәҗәсе;

башлангыч түләүнең, шулай ук шуннан соңгы даими түләүләрнең күләмнәре;

нефть һәм газ ресурсларыннан, шулай ук иярчен компонентлардан нәтиҗәле һәм комплекслы файдалану - нефть бирүчәнлекнең иң соңгы күрсәткече;

хуҗалык эшчәнлегенең әйләнә-тирә табигать мохитенә, табигатьне саклау һәм табигатьне торгызу гамәлләре дәрәҗәсенә мөмкин кадәр азрак йогынты ясавы;

нефть һәм газ ресурсларын үзләштерү өчен кирәкле инфраструктура үсешенә капитал салулар күләме.

Нефть һәм газны тикшерүләргә, разведкалауга һәм чыгаруга лицензияләр, конкурслар һәм аукционнар үткәрмичә генә, турыдан-туры сөйләшүләр нәтиҗәсендә дә бирелергә мөмкин. Мондый карарлар түбәндәге очракларда кабул ителә:

әгәр предприятиеләр нефть һәм газ ятмалары булган җир асты байлыкларын үзләренең устав йөкләмәләре нигезендә файдалансалар һәм (яисә) нефть һәм газны элек беркетелгән территорияләрдә чыгарсалар;

гамәлдәге нефть һәм газ чыгаручы оешмаларның чимал базасын тәэмин итү өчен җир асты байлыкларының чиктәш кишәрлекләрен бирүнең исбатланган зарурлыгы булганда;

җир асты байлыкларыннан файдаланырга теләүчеләрнең нефть һәм газ чыганакларын эшкәртүнең шул чыганакта кулланырлык уникаль технологияләре булса;

әгәр игълан ителгән конкурска (аукционга) бер генә хокукый заттан гаризанамә керсә;

әгәр җир асты байлыкларыннан файдалануның лицензияләнүче объектлары тиешле норматив актлар тарафыннан гомуми кулланылыш өчен ябык дип белдерелсә;

әгәр лицензия хуҗасы гамәлдәге законнар нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын башка берәүгә тапшырса;

әгәр предприятиеләр средстволарын лицензияләнүче объектка эзләнү-разведкалау эшләре алып барган чорда керткән булсалар.

Әлеге статьяда күрсәтелгән очракларда лицензияләр законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

18 статья. Нефть һәм газның җир асты саклагычларын төзүгә һәм куллануга лицензияләр бирү

Нефть һәм газның җир асты саклагычларын төзүгә һәм кулла-

нуга лицензия бирү гарызнамәләре буенча һәм мондый саклагычларны төзекләндерүнең һәм куллануның техник-икътисадый нигезләүләре буенча рөхсәт ителә.

Мондый лицензияләр бирүгә гарызнамәдә әлеге максатлар өчен җир асты саклагычын төзү зарурлыгын нигезләү, булачак җир асты саклагычының урнашачак урыны һәм аның чикләре турында мәгълүмат, калган запаслар хакында белешмә ( нефть һәм газның җир асты саклагычын элек эшкәртелгән чыганакларда яисә ятмаларда төзегән очракта), җир асты байлыкларының шушы кишәрлегендә элегрәк башкарылган бүтән төрле лицензияләрдәге эшләр хакында мәгълүмат, сулы катламнарда җир асты саклагычлары төзегәндә өстәге һәм астагы катламнарны изоляцияләү буенча йөкләмәләр.

<u>19 статья.</u> Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының күчүе

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы башка эшкуарлык эшчәнлеге субъектына (юридик затка) түбәндәге очракларда күчә:

1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятиенең оештыру-хокукый рәвеше үзгәргәндә;

2) җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятиене законнар нигезендә үзгәртеп корганда.

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкәндә лицензия кабаттан рәсмиләштерелергә тиеш. Бу чакта лицензия яңадан каралмый.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятие исеме үзгәргәндә дә лицензия кабат рәсмиләштерелергә тиеш.

Лицензия җир асты байлыкларыннан файдаланучы гаризасы буенча лицензия биргән органнар тарафыннан кабат рәсмиләштерелә.

Лиаенцияне кабат рәсмиләштерү тәртибе законнарның җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия биргәндәге рәсмиләштерү һәм теркәү таләпләре нигезендә билгеләнә.

Лицензияне кабат рәсмиләштерү кире кагылса, җир асты байлыкларыннан файдаланучы суд тәртибендә шикаять белдерә ала.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы, федераль законнарда каралган очраклардан гайре, үз хокукын өченче затка тапшырырга тиеш түгел, шул исәптән хокукларга ташлама ясау тәртибендә дә.

258

20 статья. Мөлкәткә милекчелек хокукы

Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия хуҗасы тарафыннан аның үз акчалары исәбенә түзелгән яисә сатып алынган барлык күчерелә торган һәм күчерелми торган мөлкәт аның милке була.

Чыгарылган продукция рәвешендә дәүләт тарафыннан лицензия шартлары нигезендә лицензия хуҗасына суммасы кире кайтарылган мөлкәт дәүләт милке була. Бу очракта лицензия хуҗасы лицензия гамәлдә булган барлык чорда әлеге мөлкәттән махсус файдалану хокукына ия була һәм мөлкәтнең сакланышы өчен һәм аны эшчән халәттә тоту өчен җаваплы була.

21 статья. Нефть һәм газ чыгаруга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту

Әгәр нефть һәм газ чыганагын эшкәртүнең проект чоры лицензия гамәлдә булуның гамәлдәге законнарда билгеләнгән чорыннан артса, ул лицензия хуҗасы инициативасы буенча лицензия биргән органнар тарафыннан озынайтыла, әмма лицензия хуҗасы анда билгеләнгән шартларны һичшиксез үтәргә тиеш.

Нефть һәм газ чыгаруга лицензия хуҗасы, лицензиянең гамәлдә булу чоры тәмамланырга бер ел кала, аны озынайту теләге хакында язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Нефть һәм газ чыгаруга лицензиянең гамәлдә булу чорын озынайтудан нигезләнмәгән килеш баш тартсалар, аның хуҗасы әлеге гамәл хакында хөкем тәртибендә шикаять белдерергә хаклы.

Кичектермәслек хәлләр килеп туганда, нефть һәм газ чыгаруга лицензиянең гамәлдә булу чоры туктатып торылырга мөмкин. Лицензия хуҗасы җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турындагы гариза белән лицензия биргән органнарга мөрәҗәгать итмәсә, әлеге хәлләрнең нәтиҗәләре бетерелгәннән соң нефть һәм газ чыгаруга лицензия яңадан үз көченә керә.

## V бүлек.
## Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү (эзләүләр һәм бәяләү) һәм нефть, газ чыгару эшләрен алып бару үзенчәлекләре

22 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү (эзләүләр һәм бәяләү) эшләрен алып бару үзенчәлекләре

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә (эзләүләргә һәм бәяләүгә) лицензия хуҗалары үзләренә бирелгән җир асты кишәрлекләре чикләрендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

нефть һәм газ ятмалары булган катламнарның җир асты - техник, геологик-физик параметрларын, нефть, газ һәм газ конденсаты, шулай ук иярчен компонентларының үзенчәлекләрен билгеләү;

җир астындагы нефть һәм газны юк-барга әрәм итмәс өчен һәм аларның сыйфатларын киметмәс өчен җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең (эзләнүләрнең һәм бәяләүнең) ысулларын һәм алымнарын куллану;

киләчәктә файдаланырга мөмкин булмаган скважиналарны һәм башка корылмаларны билгеләнгән тәртиптә юк итү;

эшләрне хәвефсез алып бару;

җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү (эзләүләр һәм бәяләү) эшләре дәүләт тарафыннан исәпкә алынырга һәм теркәлергә тиеш. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә лицензия хуҗалары эзләү эшләре беткәннән соң һәм геологик хисап төзегәннән соң, шулай ук дәүләт экспертизасы үткәргәннән соң алынган мәгълүматларны Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондына тапшыралар.

23 статья. Эзләнү эшләренең мәҗбүри минимумы

Лицензия килешүенә эзләнү һәм бәяләү эшләренең физик рәвештә һәм акчалата билдерелгән минимумын үтәмәү турында лицензия хуҗасының җир асты байлыкларыннан файдалану чорлары буенча йөкләмәсе кертелә. Әгәр лицензия хуҗасы эзләнү эшләренең мини-

мумын башкармаса һәм минимумның яңадан каралу зарурлыгын нигезли алмаса, ул үтәлмәгән эшләр хакын дәүләткә кире кайтара.

24 статья. Җир кишәрлекләре бирү

Җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында җир кишәрлекләре биргәндә, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, икътисадый максатка ярашлылыктан һәм әйләнә-тирә мохитнең, халыкның иминлеген тәэмин итүдән чыгып, авыл хуҗалыгы җирләренең һәм закон нигезендә башка максатларда файдалану тыелган һәм чикләнгән бүтән җирләрнең өстенлеген исәпкә алып, теге яисә бу эшчәнлек йөзеннән, җир кишәрлекләрен файдалануның өстенлеген билгели.

Нефть һәм газ чыгаруга лицензияләр бирелгәндә җир кишәрлекләрен бүлеп бирү җитештерү инфраструктурасы объектларын һәм нефть һәм газны транспорт системасына кабул итеп алу ноктасына яисә кулланучыга кадәр торбаүткәргечләр төзү өчен кирәкле күләмнәрдә лицензия шартлары нигезендә бүлеп бирелә.

Нефть һәм газ чыгаруга бирелгән лицензиянең гамәлдә булу чорына җир кишәрлекләренең күләмнәрен үзгәртү буенча нигезләнгән зарурлык килеп чыккан тәкъдирдә, җир кишәрлекләре милекчеләренең һәм хуҗаларының ризалыгы белән аларның чикләре үзгәртелергә мөмкин, соңыннан күрсәтелгән лицензияләргә тиешле үзгәрешләр кертелә. Күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә корылмалар төзү лицензия хуҗалары рөхсәте белән башкарыла.

Җир кишәрлекләре милекчеләре һәм биләүчеләре арасында җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләр җир турындагы һәм гражданлык турындагы законнар белән җайга салына.

25 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү (эзләнүләр һәм бәяләү) эшләрен алып бару өчен бирелүче җир кишәрлекләрен кире кайтару

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү (эзләнүләр һәм бәяләү) эшләрен алып барганда, лицензия шартнамәсе шартлары нигезендә әлеге максатлар өчен бирелгән җир кишәрлекләре кире кайтарыла. Лицензия хуҗасы җир асты байлыкларыннан файдалан-

ганда богылган җир кишәрлекләрен яңадан файдаланырлык халәткә китерергә тиеш.

Лицензия хуҗасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен бирелгән җир кишәрлекләреннән вакытыннан алда баш тартуы зәләнү - разведкалау эшләренең мәҗбүри минимумын кечерәйтүгә китерми.

26 статья. Нефть һәм газ чыгару эшләрен алып бару үзенчәлекләре

Нефть һәм газ чыгаруга лицензия хуҗалары, шулай ук нефть һәм газның җир асты саклагычларын төзүгә һәм алардан файдалануга лицензия хуҗалары эшләнмәләрнең (технологик схеманың) расланган проектлары һәм гамәлдәге стандартлар, нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә эшләрне башкаруны тәэмин итәргә тиешләр.

Нефть һәм газны геологик зәләүгә, разведкалап бетерүгә һәм чыгаруга лицензия хуҗасы, нефть һәм (яисә) газ чыганагын ачкан очракта, мондый лицензия биргән органга кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш.

Әгәр бу чыганак лицензия хуҗасы уйлавынча сәнәгати эшкәртелергә тиеш булса, ул үзенә лицензия биргән органнарга шушы чыганакны эшкәртү проектын раслау өчен тапшырырга тиеш.

Нефть һәм газ чыганакларын эшкәртүгә куелучы төп таләпләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

экологик иминлекне һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны тәэмин итү;

катламнарның ышанычлы изоляциясен тәэмин итүче скважиналар конструкцияләрен төзү;

скважиналар төзү һәм алардан файдалану эшләрен хәвефсез башкару һәм тикшереп торуны, ачык фонтаннарны булдырмый калу һәм бетерүне тәэмин итү;

нефть һәм газның эчке һәм промыселара торбаүткәргечләренең хәвефсезлеген тәэмин итү;

нефть һәм газ җыю, катлам басымын бер дәрәҗәдә тоту системаларын куллану, заманча технологияләрне һәм техниканы, катламнарның куәтен нәтиҗәлерәк файдалануны һәм чыганаклардан нефть һәм газны күбрәк чыгаруны тәэмин итүче катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру ысулиятен гамәлгә кертү;

җир асты байлыкларыннан файдалануның лицензияле һәм геологик яктан аерым-аерым урнашкан объектларын техник һәм технологик бүлгәләү;

һәр геологик объект буенча аерым-аерым технологик параметрлар үлчәменең хакыйкый системасын тәэмичә генә техник һәм технологик яктан бүләргә мөмкин геологик объектларны эшкәртүнең бер объектына гына туплау.

Лицензия хуҗалары нефть һәм газның ачык фонтаннарына каршы көрәш буенча махсуслаштырылган бүлекчәләр һәм газ хәвефлегеннән коткару бүлекләре белән төзелгән шартнамә нигезендә аларның хезмәт күрсәтүләреннән файдаланырга тиешләр.

Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясенең башка субъектларының уртак чикләре территорияләрендә нефть һәм газ чыгаруга лицензия хуҗалары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

күрше төбәкләрнең территорияләреннән нефть һәм газ урлауларны булдырмый калу һәм туктату чараларын күрергә;

нефть һәм (яисә) газ урлау факты ачылган очракта, тиешле дәүләт органнарына бу хакта вакытында хәбәр итәргә;

нефть һәм (яисә) газ урлауны үз көчләре белән туктату мөмкин булмаганда, тиешле дәүләт органнарына кирәкле гамәлләрне башкарганда төрле яклап ярдәм итү.

## VI бүлек.
## Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлауның магистраль торбаүткаргече

<u>27 статья.</u> Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектлары

Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектлары эшкәртелүче чыганаклардан алып үзәк нефть һәм газ үткәрү магистральләренә кадәр дәүләт милкендә булырга мөмкин, шулай ук әлеге объектларны үз акчаларына яисә, оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, законда тыелмаган башка чыганаклар исәбенә төзүче яисә сатып алучы эшкуарлар милкендә булырга мөмкин.

Нефть һәм газны транспортлауның магистраль торбаүткәргече объекты милекчесе аңардан файдаланучыларның һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының әгәр аларның мәнфәгатьләренә кагылса, алдан эшләнгән язма ризалыгыннан башка әлеге объектны файдаланудан төшереп калдыра алмый һәм аның трассасын үзгәртә алмый. Мондый ризалык алган очракта, объект милекчесе аны ирекле рәвештә сатарга, аның юнәлешен үзгәртергә яисә аңа демонтаж үткәрергә хаклы.

28 статья. Татарстан Республикасы территориясе буйлап нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалары белән нефть һәм газ җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасындагы мөнәсәбәтләр

Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалар белән нефть һәм газ җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасындагы мөнәсәбәтләр шартнамәләр нигезендә билгеләнә.

Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торба үткәргеч оешмасы нефть һәм газны микъдарын һәм сыйфатын саклап калу һәм аларны илтеп җиткерүләрнең даимилеген тәэмин итү буенча барлык чараларны күрергә тиеш.

Йөк җибәрүче (йөкне кабул итеп алучы) үз гаебе аркасында башка йөк җибәрүчеләргә (нефть үткәргечтән файдаланучыларга) карата кылынган чикләү өчен яисә нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргече оешмасына китерелгән зыян өчен җаваплы була.

Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмасы үзенә мөрәҗәгать иткән һәм транспортланучы продукциягә милекчелек хокукы булган яисә тиешле сертификатларга ия һәр йөк җибәрүчегә (физик яисә юридик затка), билгеләнгән тәртиптә сөйләшенгән вакыттан да соңга калмыйча, транспорт хезмәте күрсәтә. Транспорт хезмәтләрен күрсәтү бары тик илтеп җиткерү маршрутларының оптималь хакын һәм техник мөмкинчелекләрен исәпкә алып башкарыла.

Нефть һәм газ магистраль торбаүткәргеченең үткәрү сәләте барлык нефтьне үткәрергә мөмкинлек бирмәсә, һәр йөк җибәрүче

үләренең бөтен ихтыяҗларыннан бертигез өлешне транспортлауга хаклы булалар, әгәр тиешле килешүдә башкасы каралмаган булса, бу өлеш нефтьне транспортлаучы магистраль торбаүткәргече үткәрү сәләтенең барлык йөк җибәрүчеләрнең әлеге юнәлештә транспорт хезмәтенә ихтыҗларының гомуми суммасы чагыштырмасына тигез була.

Билгеләнгән тәртиптә сөйләшенгән вакыт узганнан соң мөрәҗәгать иткән йөк җибәрүчеләр вакытында шартнамәләр төзегән йөк җибәрүчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндергәннән соң калган ирекле үткәрү сәләтенә генә исәп тота алалар.

29 статья. Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмасының җирдән файдалану үзенчәлекләре

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргече оешмалары түбәндәге хокукларга ия була:

үзләренә бирелгән җир кишәрлекләре чикләрендә, саклау зонасын исәптә тотып, җайланмаларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, һәлакәтләрне булдырмый калу һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү эшләрен башкарырга;

республика әһәмиятендәге проектларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен алганда өстенлеккә.

Транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларын һәм газ саклау өчен кирәкле объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре җир турындагы һәм гражданлык турындагы законнарда каралган тәртиптә бирелә.

30 статья. Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларын проектлау

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларын проектлау шуңа лицензиясе булган учреждение тарафыннан башкарыла.

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларын төзү һәм үзгәртеп коруның проект документлары билгеләнгән тәртиптә дәүләтнең экологик һәм техник-икътисадый

265



экспертизасын уздылар. Дәүләт экспертизалары әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан, шулай ук алар кушуы буенча экспертиза үткәрергә хокукы булган бәйсез оешмалар тарафыннан үткәрелә.

31 статья. Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларыннан файдалану

Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектлары милекчеләре үз объектларыннан мөстәкыйль файдаланалар йә нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалары белән тиешле объектларны хуҗалык итү өчен тапшыру турында шартнамәләр төзиләр.

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларыннан файдалану билгеләнгән тәртиптә бирелүче лицензия нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларыннан файдалану билгеләнгән тәртиптә расланган техник, янгын куркынычсызлыгы, экологик иминлек, магистраль торбаүткәргечләрдән файдалану, табигый байлыклардан файдалану һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы кагыйдәләр һәм үтәлүе мәҗбүри булган башка норматив актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектлары милекчеләре түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

техник эксплуатация кагыйдәләре нигезендә магистраль торбаүткәргечләрнең техник халәтенә диагностик контрольне;

нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларына норматив актларда билгеләнгән тәртиптә даими рәвештә техник аттестация үткәреп торуны;

гамәлдәге норма һәм кагыйдәләр таләпләре нигезендә куелган һәм хезмәт күрсәтелүче контроль-исәпләү приборлары белән магистраль торбаүткәргечкә җибәрелүче нефтьнең һәм газның микъдарын исәпләүне;

нефть һәм газ торбаүткәргечләрендәге һәлакәтләрне исәптә тоту, шулай ук алар хакындагы белешмәләрне магистраль торбаүт-

кәргечләрнең хәвефсезлек, аларны саклау һәм техник куллану кагыйдәләре һәм башка норматив актлар нигезендә вәкаләтле органнарга тапшыруны;

энергия ресурсларын саклау һәм икенчел энергетика ресурсларын файдалы эшкә тоту гамәлләрен;

һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү гамәлләрен финанслау өчен нефть һәм газ торбаүткәргечләрен һәлакәт очракларыннан мәҗбүри иминләштерүне.

Әгәр нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргечен энергия белән тәэмин итүне чикләү әлеге магистраль торбаүткәргечтән файдалану иминлеген бозса, энергия белән тәэмин итү оешмаларына бу гамәлне башкару тыела.

<u>32 статья.</u> Бер үк техник коридорда коммуникацияләре үтүче яисә кисешүче нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларының үзара мөнәсәбәтләре

Бер үк техник коридорда коммуникацияләре үтүче яисә кисешүче нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалары әлеге коммуникацияләрдән ышанычлы һәм хәвефсез файдалануны тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрен үзара шартнамәләр нигезендә җайга салалар.

<u>33 статья.</u> Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларында исәпкә алу-хисап тоту вакыты

Кайда урнашуларына карамастан, нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларында исәпкә алу-хисап тоту вакыты Мәскәү вакыты белән күрсәтелә.

34 статья. Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларында эшләрне алып бару һәм аралашу теле

Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларында эшләрне алып бару, исәпкә алу, хисап тоту, коммерция һәм техник документлар рус телендә башкарыла. Оператив элемтә барышында да рус теле кулланыла.

Хокукый һәм фәнни-техник мәгълүмат алмашканда, шулай ук диспетчер элемтәсе, телефон, телефакс, факсимиль элемтә һәм элемтәнең башка чаралары аша хезмәт өчен аралашу инициатор телендә, кирәк чакта, рус һәм татар телләренә тәрҗемә итеп башкарыла.

Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларындагы барлык өскорма язулар, шул исәптән мәгълүмати һәм реклама билгеләүләре, шулай ук нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларының исемнәре рус һәм татар телләрендә языла. Җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, башка телләр дә кулланылырга мөмкин.

35 статья. Нефть һәм газ транспортлаудан баш тарту

Татарстан Республикасы территориясендә чыгарылучы нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалары түбәндәге сәбәпләр аркасында нефть һәм газ транспортлаудан баш тартырга хаклы:

йөк җибәрүченең транспорт хезмәтләренә гарызнамәсе булмаса;

йөк җибәрүче, билгеләнгән процедураларны һәм вакытны бозып, гарызнамә биргән булса;

транспортлау өчен тәкъдим ителгән продукт куыла торган продуктка сыйфаты һәм башка характеристикалары буенча туры килмәсә (куыла торган продуктларның туры килү-килмәве билгеләнгән тәртиптә ачыклана).

Башка сәбәпләр аркасында нефть һәм газ транспортлаудан баш тарту рөхсәт ителми.

Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч

оешмалары, йөк җибәрүчеләрнең нефть һәм газга карата милекчелек хокукын яисә аларны экспортка чыгару хокукын раслаучы документлары булмаса, нефть һәм газны транспортлый алмыйлар.

## VП бүлек.
## Татарстан Республикасының җир астыннан чыгарылучы нефть һәм газны сату

36 статья. Нефть һәм газны сату

Татарстан Республикасының җир астыннан чыгарылучы нефть һәм газны сату билгеләнгән тәртиптә расланган эшкәртү проектлары һәм технологик схемалар буенча җитештерүче тарафыннан исәпләнгән һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы нефть һәм газ чыгару күләмнәре нигезендә башкарыла.

Чыгарылучы нефтьне уртак предприятиеләр, нефть компанияләре, физик затлар тарафыннан сату контрактлар, шартнамәләр һәм башка үзара йөкләмәләр нигезендә башкарыла.

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы мәнфәгатьләреннән чыгып, нефть сатуның еллык күләмнәренә үзгәрешләр кертә алалар.

## VШ бүлек.
## Татарстан Республикасы территориясендә Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы эшчәнлеге үзенчәлекләре

37 статья. Татарстан Республикасы территориясе буенча Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы идарәсе

Татарстан Республикасы территориясендә Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы идарәсе органы түбәндәгеләрне башкара:

газ чыгаручы, газ эшкәртүче һәм газ транспортлаучы оешмалар арасында технологик һәм оештыру элемтәләрен;

газ һәм газ конденсатына ихтыяҗларның агымдагы һәм киләчәк күләмнәрен фаразлау, әлеге ихтыяҗларны канәгатьләндерү ысулларын билгеләү;

дәүләт ихтыяҗларын исәпкә алып, газ һәм газ конденсаты балансын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы кулланучыларын газ белән ышанычлы тәэмин итү;

газ агымнарына үзәкләштерелгән оператив идарәне һәм төзелгән шартнамәләр кысаларында чит оешмалар өчен газ белән тәэмин итү һәм газдан файдалану режимнарын билгеләү;

Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасын үстерү һәм үзгәртеп кору буенча бердәм фәнни-техник һәм инвестицион сәясәт уздыру.

38 статья. Газ җитештерүчеләр белән газ транспортлау системалары оешмалары арасындагы мөнәсәбәтләр

Газ җитештерүчеләр белән газ транспортлау системалары оешмалары арасындагы мөнәсәбәтләр газ транспортлау системасына керүгә рөхсәт нигезендә, шулай ук газ җитештерүчеләр, газ транспортлау системасы оешмалары һәм газ кулланучылар арасында төзелгән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы территориясендә әлеге рөхсәтләрне бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасына кермәгән җитештерүчеләр газын транспортлау гамәлдәге шартнамәләр буенча газ транспортлауга, бүлүгә һәм илтеп җиткерүләргә комачауламаска тиеш. Әлеге җитештерүчеләр газын транспортлау хакын түләү бердәм тариф системасы буенча башкарыла.

39 статья. Татарстан Республикасы территориясендә Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы оешмалары белән газ кулланучылар арасындагы мөнәсәбәтләр. Кулланучыларга бирелүче газ күләмен исәпкә алу

Татарстан Республикасы территориясендә Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы оешмалары белән газ кулланучылар ара-

сындагы мөнәсәбәтләр газ бирү һәм куллануның билгеләнгән тәртиптә расланган кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Контроль исәпләү приборларының тиешенчә һәм дөрес эшләүләре өчен оешма житәкчеләре, шулай ук газ кулланучы гражданнар җаваплы була.

Газ кулланучылар Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасы вәкилләренә Татарстан Республикасы территориясендә теләсә кайсы вакытта әлеге приборларга керү һәм аларны тикшерү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиешләр.

Газ тәэминаты объектларын төзүче һәм аларны кулланылышка вакытында тапшырмаучы газ кулланучылар газ җибәрүчеләргә газ үткәрүне һәм газ бүлүне тоткарлау белән бәйле югалтуларны компенсациялиләр.

Газдан куллана башлаучыларны газ тәэминаты системасына тоташтыру алар газдан файдалануга Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләт биргән органнан рөхсәт алганнан соң гамәлгә ашырыла.

40 статья. Газны бүлү

Газны агымдагы һәм фаразлаучы баланслар һәм лимитлар (квоталар) буенча бүлү законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана.

Газны ягулык буларак куллану буенча өстенлекле хокукка әлеге газ бирелергә тиешле түбәндәге газ кулланучылар ия:

халык;

җәмәгать туклануы, сәүдә һәм җәмгыяви-көнкүреш хезмәте күрсәтү оешмалары;

дәвалау-савыктыру, санитар-гигиена, мәгариф оешмалары, шул исәптән мәктәпкәчә оешмалар һәм учреждениеләр;

коммуналь һәм мәдәни өлкәдәге оешмалар.

Газ тәэминаты өстенлегенә тагын түбәндәгеләр ия була: агросәнәгать комплексы оешмалары, башка ягулыкка көйләп булмый торган җайланмалары булган газ кулланучы сәнәгать оешмалары.

171



## IX бүлек.

## Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан нефть чыгару һәм газ сәнәгате объектларының, нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларының хәвефсезлеге

41 статья. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан нефть чыгару һәм газ сәнәгате объектларының, нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларының хәвефсезлеген тәэмин итү таләпләре

Нефть чыгару һәм газ сәнәгате объектларының, нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларының хәвефсезлеген тәэмин итүнең теп таләпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

күрсәтелгән объектлардан файдалануны һәм аларның хәвефсезлеген тәэмин итү чараларын тотуны проектлар, нормалар, техник шартлар һәм кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашыру;

хәвефсез эшчәнлекне тәэмин итү, мөмкин булган һәлакәт очракларының нәтиҗәләрен бетерү һәм азайту буенча махсус гамәлләр комплексын проектлар, нормалар, техник шартлар һәм кагыйдәләр составына кертү;

чит затларның һәм оешмаларның әлеге объектлар эшләренең иминлеген бозарлык тыкшынуларын тыю;

әлеге объектларның проектлау һәм файдалануга тапшыру стадиясендә хәвефсезлек дәрәҗәләрен билгеләү өчен дәүләт экспертизасы уздыру;

объектлардан имин файдалануны һәм аларның техник халәтен тикшереп торуны оештыру;

хәвефлелек дәрәҗәсе югары булган җитештерү мәйданнарына хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрне ел саен аттестацияләү;

әлеге объектларның әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынты ясау дәрәҗәсен бәяләүче документларга дәүләт экология экспертизасын уздыру.

42 статья. Һәлакәтләр нәтиҗәләрен бетерү эшләрен оештыру

Нефть һәм газны транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалары нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларының эшчәнлеген бозуга китергән һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү буенча кичекмәстән нәтиҗәле чаралар күрергә һәм бу хакта тиешле органнарга хәбәр итәргә тиешләр.

Нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмалары һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә ярдәм күрсәткән оешмаларга тотылган чыгымнарын, шулай ук физик һәм юридик затларга китерелгән зыянны түлиләр.

Торбаүткәргеч коммуникацияләрне туктату яисә бозу аркасында, йә әлеге оешмаларның өзлексез һәм имин эшләвен бозарлык башка гамәлләр аркасында нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч оешмаларына китерелгән зыян гаепле затлар тарафыннан законнар нигезендә түләнә.

43 статья. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан нефть чыгару һәм газ сәнәгате, нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларының иминлеген бозган өчен җаваплылык

Нефть чыгару һәм газ сәнәгате, нефть һәм газ транспортлаучы магистраль торбаүткәргеч объектларының иминлеген бозган өчен җаваплылык законнар нигезендә билгеләнә.

## X бүлек.
## Йомгаклау нигезләмәләре

44 статья. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге Закон белән җайга салынучы мөнәсәбәтләр барышында килеп чыгучы бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

45 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында

1. Әлеге Законны, 1998 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертеләчәк 10,11,12,13 статьяларыннан гайре, басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

3. "Җир асты байлыклары турында" Татарстан Республикасы Законы әлеге Законга каршы килмәгән өлешендә кулланыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 19 июне
N 1211